Министерство образования и науки Республики Татарстан
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования
«Дворец творчества детей и молодежи имени Ильдуса Харисовича Садыкова»
Нижнекамского муниципального района
Республики Татарстан

ПРИНЯТА
на заседании педагогического совета
МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
Протокол № 1
от «31» августа 2022 г.

УТВЕРЖДАЮ
Директор МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
_____________ Р.Н. Салихзянов
Приказ № 211
от «31» августа 2022 г.

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА «МИРАС»

***Направленность:*** социально-гуманитарная
***Возраст учащихся***: 15-17 лет
***Срок реализации***: 1 год (144 часа)

***Составители:***
Гилязетдинова Занфиля Загитовна,
Габдуллина Кадрия Тимерьяновна,
педагоги дополнительного образования

Нижнекамск, 2022 год

## Укыту программасының информацион картасы

| | | |
|---|---|---|
| **1** | **Белем бирү оешмасы** | Өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” |
| **2** | **Программаның тулы исеме** | «МИРАС » |
| **3** | **Программаның юнәлеше** | социаль-гуманитар |
| **4** | **Программаны төзүчеләр турында мәгълүмат** | |
| 4.1 | Ф.И.О. | Гыйләҗетдинова З.З., Габдуллина К.Т., югары категорияле өстәмә белем бирү педагогы |
| **5** | **Программа турында мәгълүмат:** | |
| 5.1 | гамәлгә ашыру вакыты | 1 ел |
| 5.2 | укучыларның яше | 15-17 яшь |
| 5.3 | Программага характеристика:<br>программаның тибы<br>программаның төре<br>программаны проектлау принциплары<br>укыту процессын оештыру эчтәлеге формасы | үстерелешле өстәмә гомуми белем бирү программасы<br>модификацияле<br><br>музей дәресе, дәресләр |
| 5.4 | Программаның максаты | укучыларны халкыбызның тарихи үткәне, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру;<br>милләтебезнең күренекле шәхесләре, якташларыбыз иҗаты белән тирәнтен таныштыру, аларга хөрмәт хисләре тәрбияләүгә юнәлеш бирү |
| **6.** | **Белем бирү программасының формалары һәм алымнары** | Балалар берләшмәсе.<br>Проблемалы эзләү ысуллары, мөстәкыйль һәм гамәли эшләр, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр;<br>сыйныфтан тыш чаралар |
| **7.** | **Нәтиҗәлелекне мониторинглау формалары** | Әңгәмә, интервью, иҗади эш, реферат, проект яклау |
| **8.** | **Программаның нәтиҗәлелеген тормышка ашыру** | |
| **9.** | **Программаны раслау һәм соңгы үзгәртү датасы** | 31.08.2022 г. |
| **10.** | **Рецензентлар** | Зиновьева Ф.М. - бүлек мөдире |

# Эчтәлек

1. Аңлатма язуы…………………………………………………………….................................4-7
2. Укыту планы
3. Программаның эчтәлеге
4. Программаның педагогик – оештыру шартларын тормышка ашыру...............20-5.
5. Кулланма әсбаплар.......................................................................................36. 6.
6. Кушымталар.................................................................................................35

Кушымта 1. Методик материал..........................................................................35

Кушымта 2. Календарь-укыту графигы....,,,,,,,,,,,......................................36-43
Кушымта 3. ТР Түбән Кама муниципаль районының “И.Х.Садыков исемендәге балалар һәм яшьләр иҗаты сарае “өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия программасын тормышка ашыру кысаларында тәрбия эше планы..........................................................................70-75

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

«МИРАС» программасы социаль-гуманитар *юнәлештәге программа.*

Программа төп *норматив документлар* нигезендә төзелде:

- Бала хокуклары турында БМО конвенциясе;
- Программа «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ;
- Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе, 31.03.20022ел, №678-р;
- “Мәгариф” милли проекты кысаларында “Һәр баланың уңышы” федераль проекты, Россия Федерациясе Президенты каршындагы стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумының 2018 елның 3 сентябрендәге 10 номерлы утырышы беркетмәсе белән расланган “Мәгариф” милли проекты;
- Россия Мәгариф министырлыгының “Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделен раслау турында” 2009 елның 3 сентябрендәге 467 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында " 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерыгы;
- РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.08.2017ел, № 816 боерыгы белем бирү эшчәнлеген, электрон белем бирүне, дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашырганда куллану тәртибен раслау турында”;
- СП 2.4. 3648-20 “санитар – эпидемиологик таләпләр”РФ Баш дәүләт санитар табибының 28.09.2020 ел, №28 карары белән расланган” балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына” дигән темага ТР Министырлар кабинеты карары;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» уставы.
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» балаларга өстәмә белем бирү программасын эшләү һәм раслау турында нигезләмә

*Программаның актуальлеге.*

Бүгенге мәктәп укучысы үзенең тормышын гаджетлардан башка күз алдына китерә алмый. Балада матур әдәбият әсәрләрен уку, алар турында оста итеп фикер әйтү, яисә укыганны дөрес итеп, эзлекле рәвештә яза белү күнекмәләре югала бара. Грамоталы итеп яза белү бервакытта үзенең актуальлеген югалтмый.

Халкыбызны милләт итеп саклаган рухи мирасыбызны балалар белеп үсәргә тиеш. Әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, киемнәре беркемне дә битараф калдырмый. Халкыбызның тарихын өйрәнү, белү укучыларның рухи дөньясын баета. Янәшәбездәге танылган шәхесләр белән танышу, аралашу да үсеп килүче буын өчен бик кирәк.

*Педагогик максатчанлык*

Тәрбия эше – мәктәптә төп юнәлешләрнең берсе. Аның төп бурычы – шәхескә тормышта үз юлын табарга өйрәтү, сәләтен үстерү.

Хәзерге чор кешесе, үзендә җаваплылык тоеп һәм гуманистик кыйммәтләрне үзләштерә барып, үз тормышын дөрес итеп төзи белергә тиеш. Балаларда бу сыйфатларны тәрбияләүдә түгәрәкләрнең дә роле зур.”МИРАС” берләшмәсе – тәрбия эшендә олы хәзинәнең мөһим бер өлеше диярgә була.Чөнки халкыбызның үткәне, бүгенгесе, гасырлар буена бөртекләп җыелып килгән акыл һәм рухи байлыгын, халкыбызның сәнгате, мәгърифәте, гореф-гадәтләре, уеннары, әхлак принциплары, тарихи истәлекләре, туган ягыбызның табигате,байлыклары, күренекле шәхесләре, һ.б. үз эченә алып өйрәнү – балаларга кешеләр арасында яшәү күнекмәләрен формалаштыруга, белемнәрен арттыруга, иҗади сәләтләрен үстерүгә мөмкинлек бирә.

*“Туган як тарихын өйрәнү”программасының башка программалардан үзенчәлеге.*

Түбәндәге программа буенча белем алган балалар төрле яктан үсеш алып, үзләренең сөйләм телен баеталар, грамоталы итеп үз фикерләрен телдән һәм язма рәвештә җиткерә алалар. Шул ук вакытта аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнәләр, мөстәкыйль эшләү буенча күнекмәләр алалар.

*Укучыларга дистанцион ярдәм күрсәтү формалары.* Программаны тормышка ашырганда , мәгълүмати һәм компьютер технологияләре, шулай ук дистанцион укыту формалары актив кулланыла. Алынган белемнәрне ныгыту, гамәли күнекмәләрне камилләштерү өчен сайтлар белән дистанцион хезмәттәшлек алып барыла.

https://tatarica.org/ru/razdely/nauka/nauchnye-obshestva/obshestvo-izucheniya-tatarstana
https://urok.1sept.ru/статьи/649223/
https://yandex.ru/images/search?text
https://www.youtube.com/watch?v=B1H9sK7h_C4
https://uchi.ru/teachers/stats/main

**ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ**

Милләтебезнең күренекле шәхесләре белән танышу, халкыбызның тарихи үткәне буенча булган белемнәрне тирәнәйтү, укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү.

*Белем бирү максаты:*

- берләшмәгә йөрүче укучыларны туган ягыбыз тарихы, күренекле шәхесләре белән тирәнтен таныштыру;
- сөйләм һәм дөрес язу буенча белем, күнекмәләр булдыру;
- укучыларда буыннар бәйләнеше, тарихи ядкарьләргә кызыксыну уяту.

*Үстерү максаты:*

- иҗади сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру;
- сайлап алынган тема буенча реферат, фәнни эшләр язу һәм аларны яклау;

*Тәрбия бирү максаты:*

- халкыбызның тарихи үткәне белән горурлану хисләре тәрбияләү;
- туган ягыбызга мәхәббәт, күренекле кешеләренә хөрмәт уяту;

- әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

*Программаның адресаты.*

*“МИРАС”* үстерелешле өстәмә гомуми белем бирү программасы 15-17 яшьлек мәктәп укучыларына исәпләп төзелгән. Дәресләр 15 кешелек төркемнәрдә үткәрелә.

*Программаның күләме* 144 *сәгать* Программа 1 ел укытуга язылган.

*Укыту процессын оештыру формалары*

Дәресләр төрле формада үткәрелә: күмәк, аерым, төркемнәрдә, катнаш, практик эшләр, музей дәресләре, очрашулар, сыйныфтан тыш чаралар, түгәрәк өстәл артында әңгәмәләр.

Укытуның төп формасы – теория һәм практиканы үз эченә алган комплекслы дәрес. Төрле бәйге һәм фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашу планлаштырыла. Дәресләр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып планлаштырыла.

*Программаны үзләштерү вакыты – 1 ел.*

*Дәресләр режимы.* Дәреснең дәвамлылыгы СП 2.4. таләпләренә туры килә.3648-20 (2.10.2, 2.10.3, 3.6. 2п). Укучылар белән дәресләр үткәрелә: 1нче ел уку- атнага 2 тапкыр 2 академик сәгать белән, тәнәфес 10 минут.

***Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре***

***<u>Метапредмет нәтиҗәләре</u>***

-төп фикерне билгеләү;
- иҗади бурычны аңлау;
- өстәмә әдәбият белән шөгыльләнү, мәгълүматны төрле чыганаклардан табу;
- эзлеклелекне саклау;
- төркемнәрдә һәм аерым эшләү;
- эшчәнлек нәтиҗәсен булдыру;
-башкарылган эшне күрсәтә белү;
-иҗади эшчәнлеккә кызыксыну булдыру,

- ***<u>Шәхси нәтиҗәләр</u>***

*Беренче уку елы ахырына укучы*:
- кирәкле терминологияне,
- сүз сәнгатен;
- сөйләү осталыгын күрсәтә белергә тиеш.

***Программаны тормышка ашыруда йомгак ясау формалары***

Укыту процессының нәтиҗәлелеген төрле аттестация формалары күрсәтә:
а) кереш контроль - сораштыру;
б) агымдагы контроль – төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр;
в) арадаш контроль – төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр, реферат һәм проект яклау;
г) йомгаклау контроле - еллык уку курсы тәмамланганнан соң, реферат яклау формасында үткәрелә.

- ***Арадаш аттестация***.

Уку елы ахырында укучылар реферат яклау формасында арадаш аттестация үтә.

**УКУ ПЛАНЫ**

| **№ п/п** | **Бүлекнең, теманың исеме** | **Сәгать саны** | | | **Аттестация /контроль формалары** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |
| 1 | Кереш дәрес. | 2 | 2 | - | Әңгәмә |
| 2 | Эпистоляр жанры | 4 | 2 | 2 | Хат язу |
| 3 | Журналистика жанрлары (интервью, мәкалә, хат, очерк, эссе, репортаж) | 16 | 8 | 8 | Һәр жанр буенча эш |
| 4 | Тел – күңел көзгесе | 16 | 8 | 8 | Сыйныфтан тыш чара |
| 5 | Музейларда халык хәтере чагылышы | 32 | 16 | 16 | Экскурсия үткәрү |
| 6 | “Гамьсез тормыш өчен тумадым мин...” | 24 | 12 | 12 | Шигырь сөйләүчеләр бәйгесе |
| 7 | Туган ягым күренекле шәхесләре белән бай | 20 | 10 | 10 | Сыйныфтан тыш чара |
| 8 | “Әйләнә сәхнә, әйләнә...” | 8 | - | 8 | Фикер алышу |
| 9 | Фәнни-практик эш язу һәм аны яклау | 20 | 10 | 10 | Фәнни конференцияләрдә чыгыш ясау |
| 10 | Йомгаклау дәресе | 2 | 2 | | Әңгәмә |

## Программа эчтәлеге

**1 нче тема. Кереш дәрес.**
**Теория.** Түгәрәккә йөрүче укучыларны барлау, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен искә төшерү, уку елы планы, бүлек планына кертелгән кичә, бәйгеләр белән таныштыру. Берләшмәнең максаты һәм бурычлары. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.
Кереш контроль – сораштыру, әңгәмә.
**2нче тема. Эпистоляр жанры.**
**Теория.** Эпистоляр жанрның үзенчәлекләре белән танышу. Күренекле әдипләрнең шушы жанрга караган әсәрләрен уку, әһәмиятен билгеләү.
**Практика.** Хат язу.

**3нче тема. Журналистика жанрлары (интервью, мәкалә, хат, очерк, эссе, репортаж)**
**Теория.** Журналистика жанрлары белән танышу. Һәр төрнең аерым үзенчәлекләрен өйрәнү. “Туган як” газетасының структурасы белән танышу, рубрикаларны билгеләү.
**Практика.** “Туган як” газетасында басылган язмаларның жанрларын билгеләү, аларга хас үзенчәлекләрне табу. Мәкалә язу күнекмәләре.

**4 нче тема. Тел – күңел көзгесе.**
**Теория.** Телнең иҗтимагый күренеш икәнлеген аңлату. Төрки телләр турында мәгълүмат бирү. Николай Баскаковның төрки телләр классификациясе таблицасы белән танышу.
**Практика.** Танылган әдипләрнең тел турында язылган фикерләрен табу һәм уку. Төбәктәш шагыйрьләрнең тел турында язылган шигырьләрен уку. Тугандаш төрки әдәбияты әсәрләреннән өзекләр уку.
Халыкара туган тел көненә сценарий язу. 21 нче февральдә шәһәребезнең “Дуслык йорты”ннан төрле милләт вәкилләрен чакырып, “Тел – күңелем көзгесе” дигән темага сыйныфтан тыш чара үткәрү.

**5 нче тема. Музейларда халык хәтере чагылышы.**
**Теория.** Мәктәп музеена экскурсия. Андагы экспозицияләргә күзәтү ясау. Ата-бабаларыбызның эш кораллары, киемнәре белән танышу.
**Практика.** Музейдагы экспонатлар буенча мәгълүмат туплау. Экспонатлар турында Интернет материалларын өйрәнү. Экскурсия үткәрү буенча текст язу һәм аны сөйләп карау.

**6 нчы тема. “Гамьсез тормыш өчен тумадым мин...”**
**Теория.** Фатих Кәрим эзләре буенча экскурсиядә катнашу. Шагыйрьнең тормыш юлы буенча мәгълүмат бирү. Иҗатына хас үзенчәлекләр белән танышу. Ф.Кәрим турында фильм карау.

**Практика.** Интернет материалларын җыю, кызыклы фактлар буенча фикер алышу. Викторина үткәрү. Бөек Ватан сугышы чоры шигырьләрен уку һәм анализлау. Фатих Кәримнең иҗатына хас үзенчәлекләрне табу. “Фатих Кәрим шигырьләрен яттан сөйлә!” дигән шигырь сөйләүчеләр бәйгесе үткәрү.

**7 нче тема. Туган ягым күренекле шәхесләре белән бай.**
**Теория.** Туган як тарихы турында мәгълүмат бирү, күренекле шәхесләре, аларның шәһәр үсешенә керткән өлешләре белән танышу.
**Практика.** Шәһәр музеена экскурсиягә бару. Түбән Каманың Мактаулы гражданнарына багышланган Аллеядә булу. Мәктәп музеенда шәһәребезнең күренекле кешеләре белән очрашу.

**8 нче тема. “Әйләнә сәхнә, әйләнә...”**
**Теория.** Татар театры тарихы буенча әңгәмә Беренче татар театр труппалары. Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар драма театры тарихы турында лекция тыңлау. Артистлар турында мәгълүмат алу.

**Практика.** Спектакльләр карау һәм алар турында фикер алышу.

**9 нчы тема. Фәнни-практик эш язу һәм аны яклау**
**Теория.** Фәнни-практик эш структурасы белән танышу. Фәнни эшкә булган таләпләрне өйрәнү. Һәрбер бүлекнең урынын билгеләү, кулланылган әдәбиятны дөрес итеп яза белү.
**Практика.** Теманы сайлау һәм аны өйрәнү, актуальлеген билгеләү. Тема буенча мәгълүмат туплау һәм аны системалаштыру. Презентация ясау. Аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнү. Конференциядә катнашу.

**10 нчы тема. Йомгаклау дәресе**
**Теория.** Түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау. Фикер алышу.

## ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДА ПЕДАГОГИК ШАРТЛАР

**Материаль-техник база:**
1.Җылы, иркен бүлмә.
2. Җиһазлар:
- укучылар өстәле - 15 данә;
- укучылар урындыгы – 30 данә;
- укытучы урындыгы – 1 данә;
- укытучы өстәле -1 данә;
- такта – 1 данә;
- шкаф – 1 данә.
3. ТСО чаралары:
- ноутбук -1 данә;

- колонкалар - 2 данә;
- мультимедиа.
4. Материаллар һәм җиһазлар:
- тарату материаллары( схемалар, шаблоннар)
-информацион материаллар, карточкалар, методик эшләнмәләр, әдәби әсәрләр, матбугат басмалары: журналлар, буклетлар, альбомнар, аудиоязмалар.

**“МИРАС” берләшмәсенең календарь-укыту графигы**

| № п/п | Дәресне үткәрү вакыты | | Дәрес формасы | Сәгать саны | Дәреснең темасы | Үткәрү урыны | Тикшерү ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | план буенча | фактик | | | | | |
| 1. | | | дәрес-презентация | 2 | **Кереш дәрес.** Кереш дәрес. Курсның максаты һәм бурычлары.Балалар белән танышу. Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре. Берләшмәнең планы белән танышу. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | |
| 2. | | | дәрес-презентация | 2 | **Эпистоляр жанр** белән танышу. Аңа хас булган үзенчәлекләр. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 3. | | | дәрес-презентация | 2 | Әдәбиятта эпистоляр жанрда иҗат ителгән әсәрләрдән (А.С.Пушкин, Г.Кутуй) өзекләр уку, Ф.Кәрим, М.Җәлилнең хатлары белән танышу | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Хат язу |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | | | дәрес-презентация | 2 | Журналистика жанрлары (интервью, мәкалә , очерк, эссе, репортаж) | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 5. | | | дәрес-презентация | 2 | Мәкалә. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Мәкалә язу |
| 6. | | | дәрес-презентация | 2 | Интервью. Әңгәмә өчен дөрес сораулар бирергә өйрәнү. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Интервью алу өчен сораулар төзү |
| 7. | | | дәрес-презентация | 2 | Интервью. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сыйныфташлардан интервью алу |
| 8. | | | дәрес-презентация | 2 | Очерк. Сурәтләмә. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сайлап алган темага очерк язу |
| 9. | | | дәрес-презентация | 2 | Эссе. Авторның шәхси кичерешләре. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | 10-12 җөмләдән торган эссе язу |
| 10. | | | дәрес-презентация | 2 | Репортаж. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Мәктәпнең спорт залыннан репортаж ясау |
| 11 | | | дәрес-презентация | 2 | “Туган як” газетасына күзәтү ясау. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Газетага мәкалә язу |
| 12 | | | дәрес-презентация | 2 | Тел – иҗтимагый күренеш | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 13 | | | дәрес-презентац | 2 | Төрки телләр.<br><br>Тугандаш төрки | 27 нче мәктәп, 17 нче | Н.Баскаков табл.өйрәнү |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ия | | әдәбияты әсәрләреннән өзекләр уку. | кабинет | |
| 14 | | | дәрес-презентация | 2 | Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел... | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Тел турында афоризмнар табу |
| 15 | | | дәрес-презентация | 2 | Тел турында танылган шәхесләрнең фикерләре | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Индивидуаль биремнәр |
| 16 | | | дәрес-практикум | 2 | Төбәктәш шагыйрьләрнең тел турында язылган шигырьләрен уку. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Бер өзекне сәнгатьле итеп укрга өйрәнү |
| 17 | | | дәрес-презентация | 2 | Сәнгатьле уку бәйгесе | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Шигырь ятларга |
| 18 | | | дәрес-презентация | 2 | Халыкара туган тел көненә әзерләнү. Сценарий төзү | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Халыкара туган тел көненә сценарий төзергә |
| 19 | | | Сыйныфтан тыш чара | 2 | Халыкара туган тел көненә сценарий язу. 21 нче февральдә шәһәребезнең “Дуслык йорты”ннан төрле милләт вәкилләрен чакырып, “Тел – күңелем көзгесе” дигән темага сыйныфтан тыш чара үткәрү. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Аралашу; чара турында газетага мәкалә язу |
| 20 | | | Экскурсия | 2 | Мәктәп музеена экскурсия | Мәктәп музее | Күзәтү |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | | | Әңгәмә | 2 | “Әбиемнең сандыгында нәрсәләр бар?” | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 22 | | | Әңгәмә | 2 | Сөлгеләр - халкыбызның милли бизәкләре | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 23 | | | Лекция | 2 | “Татар халык киемнәре” | 21 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 24 | | | Очрашу | 2 | Төрле милләт киемендәге курчаклар (Оста Павлинова Л. Н.белән очрашу) | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 25 | | | Әңгәмә | 2 | Татар халкының аяк киемнәре (чигелгән читекләр) | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 27 | | | Әңгәмә | 2 | Бу калфаклар, түбәтәйләр... | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 28 | | | Әңгәмә | 2 | Иске китаплар... | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 29 | | | Экскурсия | | “Бер китап эзеннән...” | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 30 | | | Әңгәмә | 2 | Бабаларыбызның эш кораллары | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 31 | | | Әңгәмә | 2 | Туку станогы (тукылган паласлар) | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Күзәтү |
| 32 | | | Әңгәмә | 2 | Талдан үрелгән эшләнмәләр (тырыс, бишек, читән) | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 33 | | | Практик эш | 2 | Экспонатлар турында сөйлибез | Мәктәп музее | Күзәтү |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 34 | | | Практик эш | 2 | Экспонатлар турында сөйлибез | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 35 | | | Әңгәмә | 2 | Татар гармуннары тарихы | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 36 | | | Әңгәмә | 2 | Халкыбызның милли йолалары | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 37 | | | Экскурсия | 2 | Фатих Кәрим эзләреннән... | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 38 | | | Лекция | 2 | Шагыйрьнең Казандагы тормышы | Мәктәп музее | Күзәтү |
| 39 | | | Дәрес-презентация | 2 | «Калининград туфрагына төреп, куенында саклый Җир-Ана” | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 40 | | | Әңгәмә | 2 | Тоткынлык чоры иҗаты | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 41 | | | Әңгәмә | 2 | “Бөек җыр ул, бөек Ватан өчен сугыш кырларында үлүе”(Фатих Кәримнең сугыш чоры иҗаты) | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 42 | | | Әңгәмә | 2 | Шагыйрь кызы истәлекләре | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 43 | | | Әңгәмә | 2 | Шагыйрьнең гаиләсенә язган хатлары | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 44 | | | Дәрес-презентация | 2 | Шагыйрь турында башка шәхесләр... | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 45 | | | Дәрес-презентация | 2 | Ренат Харисның “Кадрия” поэмасы | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 46 | | | Практик эш | 2 | Фатих Кәримнең тормыш юлы, иҗаты буенча реферат язу | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 47 | | | Практик эш | 2 | Фатих Кәримгә хат | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 48 | | | Конкурс | 2 | Яттан сөйлим Кәрим шигырен... | Мәктәп музее | Телдән сораштыру |
| 49 | | | Экскурсия | 2 | Шәһәр музеена экскурсия | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Күзәтү |
| 50 | | | Дәрес-презентация | 2 | “Түбән Камам – яшьлек калам» | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Күзәтү |
| 51 | | | Дәрес-презентация | 2 | Шәһәрем турында төбәк шагыйрьләре | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Күзәтү |
| 52 | | | Дәрес-презентация | 2 | “Кама таңнары” әдәби берләшмә тарихы | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 53 | | | Очрашу | 2 | Түбән Каманың Мактаулы гражданины Ханов Ф. Г.бездә кунакта | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Күзәтү |
| 54 | | | Дәрес-презентация | 2 | Түбән Каманың беренче төзүчесе Халиуллин Х.Г.ның тормыш юлы (реферат өчен | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | материал туплау) | | |
| 55 | | | Практик эш | | Түбән Каманың беренче төзүчесе Халиуллин Х.Г.ның тормыш юлы буенча реферат язу | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Күзәтү |
| 56 | | | Әңгәмә | 2 | Россиянең Атказанган табибы Исмагилов Г.Г. ның шәһәр медицина үсешенә керткән өлеше | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Күзәтү |
| 57 | | | Практик эш | 2 | “Исмагилов Г. Г. – шәһәребезнен Мактаулы гражданины” Реферат язу | 17 нче кабинет, 27 нче мәктәп | Телдән сораштыру |
| 58 | | | дәрес-экскурсия | 2 | Татар театры тарихы буенча әңгәмә Беренче татар театр труппалары | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 59 | | | дәрес-экскурсия | 2 | Әйдәп баручы татар сәхнәсе йолдызлары | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Спектакль карау һәм алар турында фикер алышу. |
| 60 | | | дәрес-экскурсия | 2 | Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар драма театры тарихы турында лекция | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Спектакль карау һәм алар турында фикер алышу. |
| 61 | | | дәрес-экскурсия | 2 | Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар драма | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Спектакль карау һәм алар турында |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | театры тарихы турында лекция | | фикер алышу. |
| 62 | | | дәрес-презентация | 2 | Фәнни-практик эш структурасы белән танышу. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 63 | | | дәрес-презентация | 2 | Фәнни эшкә булган таләпләр. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 64 | | | дәрес-презентация | 2 | Фәнни эшнең максаты һәм бурычлары, актуальлеге | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 65 | | | дәрес-презентация | 2 | Фәнни эшнең бүлекләре: кереш, төп өлеш, йомгаклау, әдәбият исемлеге, кушымталар | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 66 | | | дәрес-презентация | 2 | Теманы сайлау һәм аны өйрәнү, актуальлеген билгеләү. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 67 | | | дәрес-презентация | 2 | Материал җыю | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 68 | | | дәрес-презентация | 2 | Тема буенча мәгълүмат туплау һәм аны системалаштыру | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 69 | | | дәрес-презентация | 2 | Презентация ясау. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 70 | | | дәрес-презентация | 2 | Аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнү. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 71 | | | дәрес-презентация | 2 | Конференциядә катнашу. | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Сорау-җавап |
| 72 | | | дәрес-презентация | 2 | Йомгаклау дәресе | 27 нче мәктәп, 17 нче кабинет | Әңгәмә |
| | | | **Барлыгы** | **144** | | | |